| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.11.2020 № 700-пр

Казан ш

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән расланган Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
11.11.2020 № 700-пр
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр - юридик яки физик затлар, шәхси эшкуарлар.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат эш йөртә.

1.3. Дәүләт хезмәтен түбәндәгеләр күрсәтә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) - җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында үтенеч язуын карау өлешендә (алга таба – үтенеч язуы), җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – ТР МК) - җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында карар кабул итү өлешендә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән «Калинин» тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлегенең белешмә телефоннары (алга таба - Бүлек): 221-40-36, 221-40-37, 1-49 (эчке), 1-50 (эчке).

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Министрлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, шулай ук, электрон почтасы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына, «Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмати системасына һәм Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Мәгълүмати стендларга һәм Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (подпунктта) дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге (реквизитлары һәм рәсми басылу чыганаклары күрсәтелеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5. Әлеге регламент түбәндәге очракларга карамый:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яки андый җирләрдәге җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү;

торак пунктлары җирләрен яки андый җирләрдәге җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү, шулай ук җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категорияләрдән торак пунктлар җирләренә күчерү;

аеруча саклана торган территорияләрнең җирләрен яки андый җирләрдәге җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү, шулай ук җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категорияләрдән аеруча саклана торган территорияләр җирләренә күчерү;

саклагыч урманнар алган урман фонды җирләрен яки андый җирләрдәге җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү, шулай ук җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категорияләрдән урман фонды җирләренә күчерү;

су фонды җирләрен яки андый җирләрдәге җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү, шулай ук җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категорияләрдән су фонды җирләренә күчерү.

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк, МФЦ) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә җавап бирә һәм «бер тәрәзә» принцибында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, оештыруда вәкаләтле, дәүләти яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән оешма (шул ук вакытта автоном учреждение булып тора);

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);»;

«бер тәрәзә» принцибы – гариза бирүченең дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән запрос белән мөрәҗәгатеннән соң аңа дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү принцибы, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар белән, муниципаль хезмәтләре күрсәтүче органнар белән арадашлыкны күпфункцияле үзәк норматив хокукый актлар һәм аралашлык турында килешүләр нигезендә гариза бирүченең катнашыннан башка үзе башкара;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) алар нигезләнгән документлардагы мәгълүмат белән туры килмәвенә китергән Министрлык җибәргән хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында үтенеч язуы (алга таба – үтенеч язуы) - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау. Үтенеч язуының киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү | Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);<br>Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК);<br>«Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабреннән 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 172-ФЗ);<br>“Кадастр эшчәнлеге турында” 2007 елның 24 июлендәге № 221-ФЗ Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары |

| | | |
|---|---|---|
| | | белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.26[1] п. (алга таба – Нигезләмә) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Министрлык - үтенеч язуын карау, җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү өлешендә;<br>ТР МК - җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында карар кабул итү өлешендә. | 3.3.26[1] п. Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары.<br>Үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат | РФ ҖК 8 ст.; РФ ҖК 8 ст.;<br>№ 172-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган дркументларны җирү (юллау) Министрлыкка үтенеч язуы һәм документлар кергән көннән башлап 37 эш көне эчендә күрсәтелә. Моңа түбәндәгеләр керә:<br>Министрлык тарафыннан үтенеч язуын карау һәм җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын яки үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат әзерләү, болар 17 эш көне эчендә башкарыла;<br>ТР МК тарафыннан җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында карар кабул ителү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты нигезендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрәстүне туктатып тору сроклары каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны (Татарстан Республикасы | № 172-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | Министрлар Кабинеты карары күчермәсе) Министрлык гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны үтенеч язуында күрсәтелгән юл белән (почта аша яки электрон адрес) тапшыру күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) Министрлыкка кергәннән һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе регистрацияләнгәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны тапшыру тәртибе | Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү өчен Министрлыкка түбәндәгеләр бирелә:<br>1. Үтенеч язуы (1 кушымта);<br>2. Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документларның күчермәләре (гариза бирүчеләр – физик затлар);<br>3. Җир кишәрлегенең хокуклы иясенең бер категориядәге җирләр составыннан башкасына күчерүгә ризалыгы, җир кишәрлегенең хокуклы иясе булып әлеге җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле сервитут урныштырылу турында килешү төзелгән зат торуы чыгарылма булыр тора;<br>4. Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен | № 172-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | раслаучы документ<br>Физик затлар, шул исәптән, юридик зат вәкилләре һәм шәхси эшмәкәрләр персональ мәгълүматны эшкәртергә ризалык бирәләр.<br>5. Тиешле тәртиптә расланган җир рекультивациясе проекты (җир кишәрлеген № 172-ФЗ Федераль законның 9 статьясының 2 кисәге нигезендә күчерелгән очракта).<br>Үтенеч язуына беркетелгән документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланмаган булса, аларның төп нөчхәсе күрсәтелә һәм аларны Министрлык белгече таныклый.<br>Үтенеч һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь форматта түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);<br>почта аша. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт | № 172-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| органнарында һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган оешмаларда саклanган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында саклanган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ).<br>2. Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) өземтә яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрының язу бите, ТР буенча ФСХИдан.<br>3. Җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРН) өземтә яки җир кишәрлеге турында ЕГРНда соралган белешмәнең булмавы турында белдерү кәгазе, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастровая палатасы” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан (алга таба – “ТР ФКП” ФБУ).<br>4. Федераль законнарда каралган очракта, дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгыннан. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. Җирләр яки җир кишәрлекләрен соралган максатчан кулланунын расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территориянең планировкасы буенча документациясенә туры килүен раслаган белешмә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм коммуналь хуҗалык министрлыгыннан һәм күчерү күздә тотылган җир кишәрлеге урнашкан территория муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органыннан.<br>Гариза бирүчеләр түбәндәге очракларда өстә күрсәтелгән документларны үзләре тапшыра ала:<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлына үтенеч язуы тапшырганга кадәр бер айдан да элегрәк алынмаган булуы шарт;<br>Җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлына үтенеч язуы тапшырганга кадәр алты айдан да элегрәк алынмаган булуы шарт. | “Экология экспертизасы турында», 23 ноябрь, 1995 ел, № 174-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне, гамәлләр башкару таләп итү;<br>Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен түләү кертелүен раслаган документларны сорау. “Дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында" 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар искәрмә булып тора;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 кисәгендәге 4 пункты чыгарылма булып тора | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр, шул исәптән:<br>Үтенеч язуын караудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Үтенеч язуы белән тиеш булмаган зат мөрәҗәгать иткән. | РФ ҖК;<br><br>№ 172-ФЗ Федераль закон, 3 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Үтенеч язуына составы, формасы һәм эчтәлеге белән Җир буенча законнар таләпләренә туры килмәгән документлар беркетелгән.<br>Түбәндәге шартларның берсе генә блуса да, җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту өчен нигез булып тора ала:<br>1) федераль законнар нигезендә җирләрне яки җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерүгә чикләүләр яисә андый күчерүнең тыелган булуы;<br>2) дәүләт экология экспертизасының тискәре бәяләмәсе булуы (федераль законнарда аны үткәрү каралган очракта);<br>3) җирләр яки җир кишәрлекләрен соралган максатлардан куллануның расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территориянең планировкасы буенча документациясенә туры килмәве ачыклануы | № 172-ФЗ Федераль закон, 4 ст. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан оешмалар биргән документ (документлар) турында белешмә | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешманыд хезмәтен регистрацияләү срогы һәм | Үтенеч язуы һәм документлар кергән көнне.<br>Документлар оригиналда тапшырыла.<br>Электрон формада хезмәт күрсәтелми | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе, шул исәптән электрон формада | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору урыннарына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урынына, аларны тутыру үрнәкләре һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчне зарури документлар исемлеге урнаштырылган мәгълүмати стендларның урныштырылуына һәм әлеге хезмәт күрсәтелү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар куелган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла.<br>Инвалидларны, шул исәптән, кресло-арба һәм озатып йөрүче эт кулланучыларны, объектларга үтеп керү һәм хезмәт алу мөмкинлеге белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла. Моңа түбәндәгеләр дә керә:<br>бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук, аларда күрсәтелгән хезмәтләргә каршылыксыз үтү шартлары;<br>Министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба –№ 181-ФЗ Федераль закон);<br>«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары)»; |

| | | |
|---|---|---|
| | мөмкинлеге, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән, кресло-арба кулланып;<br>күз күрү һәм мөстәкыйль йөри алу функцияләре бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br><br>инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә каршылыксыз керә алу һәм хезмәт күрсәтү мөмкинлеге өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын уңайлы урыннарда урнаштыру;<br><br>дәүләт хезмәте алу өчен зарури тавыш һәм күз күреме аша бирелгән мәгълүматны, шулай ук, язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль шрифты рельефлы-нокталы билгеләре белән кабатлау, сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге № 386н боерыгы белән расланган «Озатучы этнең махсус өйрәтелгәнен раслаучы документ формасын | |

| | | |
|---|---|---|
| | раслау турында, һәм аны бирү тәртипләре» белән күрсәтелгән формада һәм тәртипләрдә махсус өйрәтелгәнлегеН раслаучы документ булса, озатучы этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга башкалар белән бертигез дәүләт хезмәте алырга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итүе | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән, тулы күләмдә), башкарма хакимият | «Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук, инвалидларга дәүләт | № 181-ФЗ Федераль закон;<br>ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары |

| | | |
|---|---|---|
| органының гариза бирүче сайлаган теләсә кайсы территориаль бүлекчәсенә (экстерриториаль принцип) дәүләти һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләренә №210-ФЗ Федераль законның 15[1] статьясы нигезендә запрос биреп алып булу яки булмау мөмкинлеге | хезмәте алуны тәэмин итүче башка шартларны үтәү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка киртәләрне үтәргә булышу.<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел;<br>Министрлык бинасының, дәүләт хезмәте | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү бүлмәләренең инвалидлар керү өчен уңайлы булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү ачыклыгы күрсәткечләренә ирешү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү дә, күпфункцияле үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән, дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү үзенчәлекләрен истә тотып (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча | Консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә мөрәҗәгать итә ала.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән, “Татарстан Республикасы дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | муниципаль хезмәтләр порталы” республика дәүләт мәгълүмати системасын файдаланып, күрсәтелми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Әлеге регламент Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

үтенеч язуын һәм документларны кабул итү һәм регистрацияләү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасы һәм эчтәлеген карап чыгу, гариза бирүчегә үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат юллау;

җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү;

проектны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау;

гариза бирүчегә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын юллау;

дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып;

дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр

буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Үтенеч язуын һәм документларны кабул итү һәм регистрацияләү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән үтенеч язуын Министрлыкка бирә.

Үтенеч язуы һәм документларның нотариус яисә төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) раслаган күчермәләре почта аша юлланырга мөмкин.

3.3.2. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече (алга таба - эш башкару бүлеге) Бүлек белгече катнашында үтенеч язуын һәм документларны кабул итә, регистрацияли һәм карап чыгу өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар үтенеч язуы һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, регистрацияләнгән һәм Бүлеккә юлланган үтенеч язуы һәм аңа беркетелгән документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече эш башкару бүлегеннән үтенеч язуын һәм документларны алгач "җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында үтеенч язуының ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында үтү бите"н (2 нче кушымта) тутыра һәм ведомоствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

гариза бирүче булган оешма - юридик зат турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИга;

гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИга;

бер категориядән башкасына күчерү күзалланган җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба - ЕГРН) бирү турында, "ТР ФКП" ФБУдан;

федераль законнарда каралган очракта, дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе бирү турында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына;

җирләр яки җир кишәрлекләрен соралган максатчан куллануның расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территориянең планировкасы буенча документациясенә туры килүен раслаган белешмә бирү турында,

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм күчерү күздә тотылган җир кишәрлеге урнашкан территория муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органына.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турындагы запрослар

3.4.2. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган белешмәләрне (документлар) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, соралган белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасы һәм эчтәлеген карап чыгу; гариза бирүчегә үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат юллау

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) алганнан соң, үтенеч язуын караудан баш тартырга әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын ачыклау өчен үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасы һәм эчтәлеген тикшерә.

Процедуралар нәтиҗәсе: үтенеч язуын караудан баш тартырга әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын ачыклау өчен үтенеч язуына беркетелгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге тикшерелү.

3.5.2. үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара: үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат әзерли һәм аның Бүлек мөдире, Җир ресурслары идарәсе башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелүен, үтенеч язуын караудан баш тарту турында хатка министр урынбасарының кул куюын һәм аны Министрлыкта Эш башкару эшчәнлеге инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллауны тәэмин итә.

Әлеге Регламентның 3.5.1, 3.5.2 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә юлланган запросларга җаваплар алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат.

3.6. Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын (алга таба – ТР МК карары проекты) әзерләү; ТР МК карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау

3.6.1. Үтенеч язуын караудан баш тарту өчен нигезләр булмаса, Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

карап чыгу: үтенеч язуын, аңа беркетелгән документларны; Министрлык юллаган запросларга килгән җавапларны (белешмәләр, документлар);

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерү;

үтенеч язуын, аңа беркетелгән документларны карап чыгу нәтиҗәләре буенча ТР МК карары проектын әзерләү һәм ТР МК карары проектын бергә юллана торган хат проекты белән бергә килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән шартларның берсе генә булса да, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында (җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән буш тарту турында) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерли.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар 3.5 пункт белән билгеләнгән процедуралар тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә җибәрелгән ТР МК карары проекты һәм аның бергә юллана торган хат проекты.

3.6.2. Бүлек мөдире ТР МК карары проекты һәм аның бергә юллана торган хат проектын карап чыга һәм килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә) юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән һәм Идарә башлыгына юлланган ТР МК карары проекты һәм аның бергә юллана торган хат проекты.

3.6.3. Идарә башлыгы әзерләнгән ТР МК карары проектын һәм аның бергә юллана торган хат проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.6.2, 3.6.3 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты, аның бергә юллана торган хат проекты.

3.6.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проектын, аның бергә юллана торган хат проектын Министрлыкның хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган ТР МК карары проекты, аның бергә юллана торган хат проекты.

3.6.5. Хокук идарәсе белгече: ТР МК карары проектына хокукый экспертиза ясый; бергә юллана торган хатны карап чыга, килештерә һәм хокук идарәсе башлыгына килештерү өчен юллый яки җитешсезлекләр булган очракта ТР МК карары проекты буенча бәяләмә әзерләп – имза кую өчен.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгына юлланган ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат.

3.6.6. Хокук идарәсе башлыгы хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча ТР МК карары проектын һәм аның белән бергә юллана торган хат проектын килештерә яки ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат яки ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе.

3.6.7. Бүлек белгеченә ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган җитешсезлекләрне бетерә һәм ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хатны килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе кисәтүләрен истә тотып төзәтелгән һәм килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юлланган ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат.

3.6.8. Хокук идарәсе башлыгы ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләрнең бетерелү фактын тикшереп чыга, ТР МК карары проектын һәм аның белән бергә юллана торган хатны килештерә.

3.6.7 һәм 3.6.8 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат проекты.

3.6.9. Бүлек белгеченә ТР МК карары проектын һәм аның белән бергә юллана торган хат проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына юлланган ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат проекты.

3.6.10. Министрның беренче урынбасары ТР МК карары проектын һәм аның белән бергә юллана торган хат проектын килештерә һәм кул кую өчен министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары белән килештерелгән, кул кую өчен министрга юлланган ТР МК карары проекты һәм аның белән бергә юллана торган хат проекты.

3.6.11. Министр ТР МК карары проекты белән бергә юллана торган хатка кул куя, проектны килештерә һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган имзаланган ТР МК карары проекты белән бергә юллана торган хат, Министр белән килештерелгән ТР МК карары проекты.

3.6.12. Эш башкару бүлеге белгече ТР МК карары проекты белән бергә юллана торган хатны регистрацияли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән бергә юллана торган хатка беркетелгән ТР МК карары проекты.

3.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ТР МК карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карап чыга.

Процедура нәтиҗәсе: Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында яисә җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба шул тәртиптә – күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар).

3.8. Гариза бирүчегә күчерү турында карарны (күчерүдән баш тарту турында карарны) юллау

Бүлек белгече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) килгәч, бергә юллана торган хат әзерли, аны имзалау өчен министрның беренче урынбасарына, эш башкару бүлегенә регистрациягә юллый. Имзаланган һәм регистрацияләнгән бергә юллана торган хат һәм күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсе белән бергә Министрлыкның эш башкару эшчәнлеге инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Министрлыкка күчерү турында (күчерүдән баш тарту турында) карар кергәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән бергә юллана торган хат бергә күчерү турында (күчерүдән баш тарту турында) карар.

3.9. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып

Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып та.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән техник хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү

3.10.1. Гариза бирүченең күчерү турында карарда техник хата китү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаны төзәтелүенә нигез булып тора.

Техник хаталарны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

күчерү турында карар;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.10.2. Күчерү турында карарда техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча гаризаны Министрлыкка гариза бирүче шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.10.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны кабул итеп ала һәм, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза һәм документлар бирелгән (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза һәм аңа беркетелгән документлар.

3.10.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты (алга таба – үзгәрешләр кертү турында карар проекты) әзерли. Үзгәрешләр кертү турында карар проекты әзерләнгәч әлеге Регламентның 3.6.2. 3.6.3, 3.6.9-3.6.12 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә мәнфәгатьләре булган теләсә кайсы заттан хата җибәрелү турында гариза алган көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: әзерләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган үзгәрешләр кертү турында карар проекты.

3.10.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан үзгәрешләр кертү турында карар килгәннән соң Бүлек белгече бергә юллана торган хат әзерли, аңа министрның беренче урынбасары кул куюын, эш башкару бүлегендә регистрацияләнүен һәм бергә бллана торган хат белән бергә үзгәрешләр кертү турындагы карарның гариза бирүчегә җибәрелүен тәэмин итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Министрлыкка үзгәрешләр кертү турында карар килгәннән биш эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән бергә юллана торган хат белән бергә үзгәрешләр кертү турында карар.

3.10.6. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, үзгәрешләр кертү турында карар проекты, үзгәрешләр кертү турында карар) Министрлыкта булган үзгәрешләр кертү турында карар нөсхәсенә беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче

башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгате.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, шулай ук, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Министрлыкка шикаять белдерә ала.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, яки гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булып та, дәүләт хезмәтү күрсәтү туктатып торылса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр кабул иткәндә юклыгы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан бәян ителгәннәрне раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре тапшырыла ала.

5.6. Шикаять регистрацияләнгәннән соң унбиш көн эчендә карала, ә Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ясалган кимчелекләрне төзәтү өчен Министрлык кылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелмәсә, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатма бирелә, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе бәян ителә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

5.12. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә бәйле мөнәсәбәтләр № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә көйләнә.

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында үтенеч язуы

_______________________________________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме әтисенең исеме яки юридик затның атамасы)

җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүне сорый _______________

_______________________________________________________________

(җирнең камәлдә булган категориясе)

гомуми мәйданы ______________________________________ гектар,

кадастр номеры ___________________________________________,

__________________________________________________ хокукларында

(гамәлдә булган хокук атамасы)

_______________________________________________________________

(җирне файдаланучы атамасы)

Татарстан Республикасының _______________________________ районы территориясендә,

(муниципаль район атамасы)

_____________________________________________________ җир категориясенә

(җир кишәрлеген күчерүне күздә тоткан категория)

______________________________________________________________ өчен.

(максатчан билгеләнеш)

Күчерүнең нигезләмәсе: территория планировкасының расланган документына туры килә __________________________________________

(реквизиты территория планировкасы документын раслау турында,

_______________________________________________________________

территория планировкасының расланган документларына үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек советы карары реквизитлары (булса))

| | | |
|---|---|---|
| Гариза бирүченең почта адресы | | |
| | | |
| Элемтә өчен телефон | | |

Әлеге үтенеч язуына документлар исемлек беркетелә.

Гариза бирүче(ләр), «___» ___________ № ______________ ышаныч кәгазе буенча вәкил(ләр) имзасы

___________________________________________________/________________________/

(гариза бирүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булса) (имза)

М.П. <*>

--------------------------------

<*> Россия Федерациясе законнары буенча мөһер булу бурычы куелган очракларда.

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

## ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү турында үтенеч язуының үтү бите

Үтенеч язуының керү (регистрация) датасы ________________________________
Гариза бирүче ____________________________________________
Регистрация (керү) номеры ______________________

| N п/п | Министрлык бүлекчәләре | Алу датасы | Имза | Бирү датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге (документларны формалаштыру һәм регистрация) | | | | |

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
________________________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

______________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, шәхси эшмәкәрнең, физик затның Ф.И.ӘИ)
_____________________________________________________________________йөзендә,
(Ф.И.ӘИ., вәкилнең вазыйфасы)
_______________________________________________________нигезендә эш итә
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаган документ атамасы)
Җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хатаның төзәтелүен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»__________ 20______ел. №_________ карарына тиешле үзгәрешләр кертелүен үтенәм

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»__________ 20______ел. №_________ карарында язылган: ________________________________________________
_________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_______________________________________________________
_______________________________________________________________________

Түбәндәге документларны беркетәм:
1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

| | |
|---|---|
| Юридик зат өчен реквизитлар *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашу урыны)* | |
| | |
| | |
| Физик зат өчен, ИП (юридик зат вәкиле) паспорт мәгълүматлары *(серия, номер, кем һәм кайчан* | |

| | |
|---|---|
| *биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),*<br>яшәү урыны адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Элемтә өчен телефон, почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында белешмә | |
| Кадастр номеры | |
| Җир кишәрлеге урнашкан урын | |

Мин, ___________________________________________________________

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү үтенеч язуы имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (ышанычнамә буенча вәкил ____ №________________

__________________________________________/________________________/

(вәкилнең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (булса) имзасы)

Гариза кабул ителде: «___»__________ 20__ ел.

_____________/_____________________________________________________/

имза (гаризаны алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

**Персональ мәгълүматны эшкәртү өчен рөхсәт**

Мин, ____________________________________________________
“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү үтенеч язуы имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Үтенеч язуы бирүченең имзасы (ышанычнамә буенча вәкил ____
№________________

________________________________________/________________________/

(вәкилнең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (булса) имзасы)

Үтенеч язуы кабул ителде: «___»__________ 20__ ел.

_____________/___________________________________________________/

имза (үтенеч язуын алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире | 221-40-36 | almaz.mubarakov@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы | 264-76-89 | Lenar.Fatterahmanov@tatar.ru |